КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 июнь г.Казань № 480

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 29 март, 161 нче карары белән расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 29 март, 161 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 25 июль, 579 нчы; 2014 ел, 21 июль, 520 нче; 2015 ел, 1 июнь, 393 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурсны үткәрүне оештыру-техник тәэмин итүне «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган оешмаларга «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 16 ноябрь, 858 нче карары нигезендә конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә субсидия бирелгән коммерциягә карамаган оешма башкара (алга таба – Оешма). Оешма түбәндәгеләрне тәэмин итә:»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Конкурсны үткәрү регламенты

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Оешма белән берлектә министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар катнашында, ел саен, 30 апрельгә кадәр, республиканы социаль-икътисадый үстерүнең аеруча әһәмиятле юнәлешләрен чагылдыручы эшчәнлек номинацияләре һәм күрсәткечләре исемлеген эшли һәм Конкурс комиссиясе рәисенә раслауга тапшыра.

Конкурс комиссиясе рәисе ел саен, 1 июньгә кадәр, конкурс нәтиҗәләре ясалачак эшчәнлек номинацияләре һәм күрсәткечләре исемлеген карап тикшерә һәм раслый.

Оешма ел саен, 30 июньгә кадәр, министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар җитәкчеләрен, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларын, эш бирүчеләр берләшмәләрен һәм һөнәри берлекләрне Конкурс комиссиясенең конкурс нәтиҗәләре ясалачак эшчәнлек номинацияләре һәм күрсәткечләре исемлеген раславы турында һәм аларның конкурста катнашучылар хакында мәгълүмат тапшырырга тиешлеге турында хәбәр итә.

Татарстан Республикасының министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары, муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыклары, эш бирүчеләр берләшмәләре һәм һөнәри берлекләре ел саен, 10 октябрьгә кадәр, Оешмага һәр номинациядә конкурста катнашучылар турында өч җөмләдән дә артык булмаган мәгълүмат тапшыра, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы – һәр номинациядә конкурста катнашучы турында тиешле материаллар белән өч җөмләдән дә артык булмаган, ләкин бердән дә ким булмаган мәгълүмат тапшыра, шул исәптән:

конкурста катнашучы турында белешмә;

конкурста катнашучы җитәкләгән предприятие (оешма) турында белешмә;

катнашучы чыгарылган номинация нигезендә, конкурста катнашучы җитәкләгән предприятие (оешма) эшчәнлеге күрсәткечләре;

катнашучыны әлеге номинация буенча конкурска чыгаруның кыскача нигезләмәсе (машинкада басылган 0,5 бит күләмендә.

Ел саен, 15 ноябрьгә кадәр:

Оешма тапшырылган материалларның тулылыгын тикшерүне, аларны төгәлләштерүне һәм тулыландыруны гамәлгә ашыра, конкурста катнашучылар (номинантлар) исемлеген формалаштыра;

Татарстанстат предприятиеләр һәм оешмаларның (икътисадый эшчәнлек төрләре буенча) рейтингын билгели, конкурста катнашучылар (номинантлар) җитәкләгән предприятиеләр һәм оешмаларны кертеп, һәм аны Оешмага юллый.

Оешма ел саен, 25 ноябрьгә кадәр, Татарстанстат тапшырган рейтинг бәяләмәсен исәпкә алып, конкурста катнашучылар (номинантлар) турында материалларны эшкәртә, системалаштыра һәм җитмәгән материалларны өстәмә рәвештә туплый.

Конкурс комиссиясе ел саен, 5 декабрьгә кадәр, конкурс номинантлары исемлеген карау буенча беренчел утырыш үткәрә, һәм анда тапшырылган мәгълүматларга экспертлар бәяләмәсе бирелә.

Оешма ел саен, 10 декабрьгә кадәр, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә Конкурс комиссиясе рәисенә тапшыру өчен конкурс лауреатларына кандидатлар турында тәкъдимнәр формалаштыра.

Конкурс комиссиясе ел саен, 15 декабрьгә кадәр:

конкурста катнашучылар турында тапшырылган материалларны һәм конкурс лауреатына кандидатлар турында тәкъдимнәрне карау буенча утырыш үткәрә;

утырышта катнашкан Конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы нигезендә ачык тавыш бирү юлы белән лауреатлар турында карар кабул итә.

Конкурс комиссиясе утырышы, анда әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашканда тулы хокуклы була.

Тавышлар тигез санда булса Конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч була.

Бу чакта конкурс лауреатлары булып кагыйдә буларак ике, әмма өчтән дә күп түгел икътисадның төрле тармаклары һәм өлкәләрендәге предприятие һәм оешмалар җитәкчеләре билгеләнә.

Ел саен, декабрьнең өченче декадасында, Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар, муниципаль берәмлекләр, эш бирүчеләр берләшмәләре, һөнәри берлекләр, фәнни оешмалар һәм берләшмәләр вәкилләре, танылган сәнәгатьчеләр һәм эшкуарлар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашында конкурс лауреатларын тантаналы бүләкләү үткәрелә.

Конкурс нәтиҗәләре массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртыла.

Конкурс нәтиҗәләре буенча ел саен министрлыкларга, дәүләт комитетларына һәм ведомстволарга, муниципаль берәмлекләргә, эш бирүчеләр берләшмәләренә, һөнәри берлекләргә, Татарстан Республикасының Милли китапханәсенә юллана торган, шулай ук һәр конкурс лауреатына тапшырыла торган истәлекле китап чыгарыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин